**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИ КҮЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«19» ноябрь 2024 ел № 98

**Би Күле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 18 июлендәге 91 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25 - ФЗ номерлы Федераль законнар, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары турында « Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 12 декабрендәге 594 номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 июлендәге 91 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (25.10.2019 елның 97 номерлы, 18.12.2019 елның 101 номерлы, 21.02.2020 елның 108 номерлы, 23.08.2023 №73, 20.06.2024 № 90 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 бүлек 7.4 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «5) белем һәм квалификация турында документ;».

2. Әлеге карарны адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Кыр күле авыл җирлеге, Би Күле авылы, Мәктәп ур., 23 йорт, Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Би Күле авыл җирлеге, Илюткино авылы, Совет ур., 14 йорт, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми

порталында, шул исәптән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Би Күле авыл җирлеге Советы рәисе А.М.Шакирова